**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Комыргуҗа авыл җирлеге Мәрҗән торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“29” март 2024 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2023 елның 29 ноябрендәге 1532 номерлы “2024 елга гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Мәрҗән торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Мәрҗән торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итәргә:

“2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган тубәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1. Торак пункт территориясен яхшырту (территорияне чистарту - Мәрҗән авылында үлән чабу; Мәрҗән авылындагы уен мәйданчыгына өстәмә койма кую материаллар сатып алу, (эш һәм хезмәт өчен түләү)).

2. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган җәмәгать юлларын төзү, ремонтлау, техник хезмәт күрсәтү (Мәрҗән авылындагы асфальт тротуарны ремонтлау (эш һәм хезмәт өчен түләү);Мәрҗән авылында (М. Җәлил урамына) юл салу өчен җимерелгән таш сатып алу; (түләү эшләре һәм хезмәтләр)).

3. Ремонт, коймалар кую, традицион күмелгән урыннарны төзекләндерү (Мәрҗән авылындагы зират территориясен чистарту (үлән чабу)).

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Мәрҗән авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы — Низамиев Ф.Ф.